| СОВЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| --- | --- |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 август 2023 ел Бишня ав. № 152

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының 2021 елның 13 июлендәге 47 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (Бишнә авыл җирлеге Советының 02.09.2022 елгы №94 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 27.12.2018 № 498-ФЗ, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Бишнә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2021 елның 13 июлендәге 47 номерлы Бишнә авыл җирлеге Советы карары белән расланган (Бишнә авыл җирлеге Советының 02.09.2022 елгы №94 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә(алга таба - Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлектәге 1 нче кушымта белән тулыландырырга:

«Бишнә авыл җирлеге Советының 13.07.2021 №47 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге

территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә 1 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар Исемлеге**

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, күпләп ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарына якын территорияләр.

6. Зират.».

2. Хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында Карар кабул итүгә вәкаләтле затларның түбәндәге исемлеген билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башлыгы.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт( авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**